Республика Татарстан
Совет Большенуркеевского
сельского поселения
Сармановского
муниципального района

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районының
Зур Нөркәй
авыл җирлеге Советы

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

05.03.2019 г. № 86

Сарман муниципаль районы Зур Нөркәй авыл җирлеге Советының 2016 елның 25 гыйнварындагы 15 нче номерлы «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы "Зур Нөркәй авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын җыю һәм куллану тәртибе турында Нигезләмә" карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 56 статьясы һәм Сарман муниципаль районы Зур Нөркәй авыл җирлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Зур Нөркәй авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Зур Нөркәй авыл җирлеге Советының 2016 елның 21 гыйнварындагы 13 номерлы «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Зур Нөркәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын җыю һәм куллану тәртибе турында Нигезләмә» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) нигезләмәнең исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
"Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Зур Нөркәй авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын куллану турында нигезләмә
2) "Үзара салым акчаларын җыю тәртибе"турындагы 5 нче кисәкне гамәлдән чыгарырга һәм муниципаль берәмлекнең аерым норматив хокукый акты белән билгеләргә.
2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында " (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы «Сарман муниципаль районы»муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Сарман муниципаль районы Зур Нөркәй авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Зур Нөркәй авыл җирлеге Советы рәисе Р.М.Гайсин